РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТА РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Буа шәһәре **КАРАР**

07.05.2026 № 174/Бк/к

Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 30 ноябрендәге 373/ Бк/к номерлы «Җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар, ирекле (волонтерлык) оешмалар белән үзара эшчәнлеге тәртибе турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Хәйрия эшчәнлеге һәм иреклелек (волонтерлык) турында» 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы Федераль законның 17.3 статьясындагы 4 өлешенең 2 пункты (20.02.2026 редакциясендә) нигезендә Буа муниципаль районы Башкарма комитеты карар чыгарды:

1. Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 30 ноябрендәге 373/ Бк/к номерлы «Җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар, ирекле (волонтерлык) оешмалар белән үзара эшчәнлеге тәртибе турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктка түбәндәге пунктча өстәргә:

« -территорияне төзекләндерү.».

1.2. 22 нче абзацның 3 нче пунктына «балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалауда катнашу» сүзләрен өстәргә.;

1.3. 3 пунктның 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гаиләгә ярдәм итү, аны ныгыту һәм яклау, күпбалалылык, традицион гаилә кыйммәтләрен саклап калу, никах институтын популярлаштыру;».

1.4. 15 пунктта «Җирле үзидарә органнары ирекле (волонтерлык) эшчәнлегенә ярдәм итәләр» сүзләрен «Дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан ирекле (волонтерлык) эшчәнлеккә ярдәм итү» сүзләренә алмаштырырга.

1.5. Пункт 3:

- түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«медицина ярдәме күрсәтүче оешмаларда медицина ярдәме күрсәтүгә ярдәм итү;

Эчке эшләр органнарына (полициягә) һәм башка хокук саклау органнарына җәмәгать тәртибен саклауда Россия Федерациясе законнары нигезендә булышлык күрсәтү.»;

- дүртенче абзацта «күрсәтү» сүзен «гадәттән тыш хәлләрне һәм алардан килгән зыяннарны бетерүдә, янгыннарны профилактикалауда һәм сүндерүдә, һәлакәттән коткару эшләрен башкаруда, шулай ук күрсәтүдә катнашу» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми рәвештә бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/, һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Буа муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://buinsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә һәм мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам

Буа муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Л.Р.Шакирҗанов